КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 1 ноябрь г.Казань № 995

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль стандартларны һәм натураль нормаларны үстерү турында» 2000 ел, 5 июль, 470 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында ветеринария хезмәте учреждениеләрен тоту чыгымнарының социаль стандартларына һәм натураль нормаларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль стандартларны һәм натураль нормаларны үстерү турында» 2000 ел, 5 июль, 470 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 ел, 30 июль, 464 нче; 2003 ел, 3 февраль, 70 нче; 2003 ел, 8 сентябрь, 479 нчы; 2004 ел, 28 апрель, 209 нчы; 2006 ел, 3 февраль, 36 нчы; 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче; 2013 ел, 21 гыйнвар, 23 нче; 2013 ел, 21 февраль, 117 нче; 2013 ел, 24 апрель, 279 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында ветеринария хезмәте учреждениеләрен тоту чыгымнарының социаль стандартларына һәм натураль нормаларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Асрау» бүлегенең 2 нче пунктындагы дүртенче абзацында татар текстында «Хуҗасыз хайваннарны» сүзләре үзгәрешсез кала;

«Социаль стандартлар» дигән 2 бүлекнең 2.3 нче пунктта татар текстында «Хуҗасыз хайваннарны» сүзләре үзгәрешсез кала;

2.1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1 нче таблица

Хуҗасыз хайваннарны махсуслаштырылган предприятиеләр тарафыннан тотып алу, транспортировкалау, асрау, исәпкә алу һәм аларның санын җайга салу чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнар нормалары стандартлары

| Норманың исеме | Исәпкә алу берәмлеге | Норманың мәгънәсе, сум* |
|---|---|---|
| Хуҗасыз хайваннарны тотып алу | бер хайванга | 350,92 |
| Хуҗасыз хайваннарны хайваннар приютына транспортировкалау һәм мотивлаштырылмаган агрессия күрсәтмәгән хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү мохитенә кире кайтару** | бер баруга | 387,72 |
| Дәвалау-профилактика чаралары (вакцинацияләү, дегельминтизацияләү, дезинсекцияләү) | бер хайванга | 538,4 |
| Хуҗасыз хайваннарны хайваннар приютында 1 календарь көн асрау (шул исәптән югалган хайваннарны үз хуҗаларына кире кайтару, шулай ук хуҗасыз хайваннарга яңа хуҗалар эзләү) | бер хайванга | 108,99 |
| Хуҗасыз хайваннарны (хатын-кыз җенесендәге) стерильләштерү | бер хайванга | 1 003,91 |
| Хуҗасыз хайваннарны (ир җенесендәге) кастрацияләү | бер хайванга | 769,72 |
| Авыр дәвалап булмый торган авырулары яки хайванның тормышы белән ярашмый торган кискен дәвалап булмый торган җәрәхәт нәтиҗәләре булган хуҗасыз хайваннарны сизмәс хәлгә китерү һәм хуҗасыз хайваннар үләксәләрен утильләштерү | бер хайванга | 773,31 |

*2020 елның 1 июле хәленә карата бәяләрдә.
**Чыгымнар нормасы бригаданың бер баруында бер үк вакытта транспортлана торган биш хайваннан кимрәк булмаган хайваннар саныннан чыгып исәпләнә».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин